**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Илбәк авылы** **№137** **«07» октябрь 2019 ел**

Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 24.04.2010 ел №91 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (12.11.2010 ел №9, 29.10.2011 ел №24, 26.11.2013 ел №70, 15.08.2014 ел №96, 29.10.2015 ел №12, 27.06.2017 №50, 17.11.2017 ел №67 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 25.12.2018 ел, № 494-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм Азнакай муниципаль районында бюджет процессы нигезләмәләрен Россия Федерациясенең гамәлдәге бюджет законнарына туры китерү максатында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советы **карар чыгарды:**

1. Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 24.04.2010 ел №91 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк _ авыл җирлеге бюджет процессы турында Нигезләмәгә 12.11.2010 ел №9, 29.10.2011 ел №24, 26.11.2013 ел №70, 15.08.2014 ел №96, 29.10.2015 ел №12, 27.06.2017 №50, 17.11.2017 ел №67 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 18.1 статья өстәргә:

«18.1. Салым чыгымнары исемлеге һәм бәяләү

1. Җирлекнең салым чыгымнары исемлеге муниципаль программалар һәм аларның структур элементлары, шулай ук муниципаль программаларга керми торган эшчәнлек юнәлешләре буенча җирлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә формалаша.

2. Авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү ел саен, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, җирлек башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә башкарыла.

3. Әлеге бәяләү нәтиҗәләре җирлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.»;

1.2. 24 статьяның 3-5 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлек бюджеты турында карар проекты буенча килешмәгән сораулар килеп туган очракта, җирлек Советы Рәисе карары белән килештерү комиссиясе төзелергә мөмкин, аңа җирлек башкарма комитеты һәм җирлек советы вәкилләренең

тигез саны керә.

4. Җирлек бюджеты турындагы карар проекты барлык кирәкле документлар һәм материаллар белән җирлек Башкарма комитеты тарафыннан җирлек Советына, эшләп бетерүгә кергәннән соң, өч эш көне дәвамында тәкъдим ителергә тиеш.

5. Җирлек Советы авыл җирлеге бюджеты турында карар проектын бер укылышта карый.».

1.3. 40 статьяның 2 пунктына «бирелә» сүзеннән соң «бюджет үтәлешенә һәм бюджет хисаплылыгына анализ булган аңлатма язуы, муниципаль йөкләмәнең үтәлеше һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләреннән файдалануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай районы Илбәк авыл җирлеге Советының бюджет, финанс, салым һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Л.Р.Әсәдуллина